# ТАТАРСТАН РАЙОННАРЫ ТОРАК ПУНКТЛАРЫ АРХЕОЛОГИЯ ИСТӘЛЕКЛӘРЕН ӨЙРӘНҮНЕҢ КАЙБЕР НӘТИҖӘЛӘРЕ (ХӘЕРБИ АВЫЛЫ МИСАЛЫНДА)

***Абдуллин Х.М.**, тарих фәннәре кандидаты,*
***Галимуллина Г.Х.**,*
***Насибуллина А.Б.***

# SOME RESULTS OF THE STUDY OF ARCHEOLOGICAL MONUMENTS OF SETTLEMENTS OF TATARSTAN DISTRICTS (ON THE EXAMPLE OF THE VILLAGE OF KIRBI)

***Abdullin Kh.M., Galimullina G. Kh., Nasibullina A. B.***

Тарихчы-археологлар Татарстан районнарында фәнни-тикшеренү эшләрен комплекслы алып баралар. Элек мәгълүм һәм яңа табылган археологик, эпиграфик, архитектура-сәнәгать объектларын өйрәнү белән бергә архив, музей материалларын һәм торак-пунктлар тарихы буенча да мәгълүматларны туплыйлар. Экспедиция эшчәнлеге нәтиҗәсендә табылган, тикшерелгән археологик һәм нумизматик материалларны төбәкне өйрәнү музейларына тапшыралар. Региональ тикшеренүләрнең аеруча актуальлеге нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Татар энциклопедиясе институтында 2015 елда төбәкне өйрәнү һәм социомәдәни тикшеренүләр үзәге оештырылды. Хәзерге вакытта үзәк эшчәнлегенең төп юнәлеше булып Татарстан Республикасы торак пунктлары тарихын өйрәнү тора. Бу эш институт хезмәткәрләре тарафыннан 1990 елларда ук башланып китә, ә 1997 елда «Татарстан Республикасы торак пунктлары» («Населенные пункты Республики Татарстан») китабы чыгарыла. Әлеге кыскача белешмәдәге республика торак пунктлары турындагы мәкаләләр 2002–2014 елларда чыккан 6 томлы «Татар энциклопедиясе»ндә дә әһәмиятле урын алалар. Кешеләрнең үз Ватаны тарихына, аның социомәдәни һәм социаль-икътисади үсешенә карата кызыксынуы (мәсәлән, авыл җирлекләрен үстерүгә зур өлеш керткән күренекле кешеләр, мәдәният, мәгариф һәм фән эшлеклеләре, хуҗалык хезмәткәрләренең биографияләрен өйрәнү һ.б.) арта бара, бу турыда күпсанлы туган якны өйрәнү эзләнүләре һәм тарихи тикшеренүләр сөйли.

2019 елда, институт хезмәткәрләре тарафыннан Татарстан Республикасының Лаеш районы

Хәерби авылы тарихын өйрәнү нәтиҗәсендә, «Хәерби авылы тарихыннан сәхифәләр» китабы басылып чыкты[1]. Археологияне чагылдырган бүлеккә аеруча ачыклык кертәсе килә. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А. Х. Халиков исемендәге Археология институты мәгълүматлары буенча[2], ТРның Лаеш районы территориясендә Хәерби шәһәрлеге, Хәерби тукталыгы һәм Хәерби акча табылдыклары археологик истәлек исәпләнә.

Хәерби шәһәрлеге (I меңьеллыкка карый) 1983 елда Мишә елгасы тирәсендәге территорияне тикшергәндә В. А. Семенов* җитәкчелегендәге Удмурт археологик экспедициясе тарафыннан ачыла. 1987 елда Т. И. Останина** «Хәербидән 0,2 км көньяк-көнбатыш тарафта, Мишә елгасының уң ярында авылдан Караеш авылы ягындагы икенче борында урнашкан шәһәрлекне тикшерә[3]. Борын итәге янында авыл халкы ел саен татарларның милли Сабан туе бәйрәмен уздыра. Шәһәрлектән төньяк-көнчыгыш тарафта 0,1 км ераклыкта элеккеге елга юлы уза, 2 км көнчыгышта Мишә елгасы ага»[4]. Шәһәрлек 1052 кв.м мәйданны били.

Сөзәклекнең көньягында һәм көньяк-көнбатышында казу эшләре вакытында баганалардан һәм казыклардан калган 28 чокыр, 14 учак һәм бер хуҗалык чокыры эзләре теркәлә. Шулай ук хезмәт кораллары, тимер, сөяк һәм таш әзерләмәләр, сөңге очлыгы, чөе кисәге, пычаклар, хәнҗәр кисәге, сандал (квадрат кисемле киселгән пирамида рәвешендә), орчык башлары (орчыкны авырайту һәм эрләгән җепне беркетү өчен кулланылган авырлык очлыгы), сөяк эшләнмәләр (тишкечләр), тигельләр (төрле материалларны кыздырып яндыру яки эретү өчен савытлар), сфера рәвешендәге бакыр аел кисәге, 2862 керамик (керәч) савытлар ватыклары табыла. Савытларның формалары һәм аларны эшләүдә кулланылган балчыкның составы, бизәкләре буенча археологлар савыт-сабаларны 3 төркем-комплекска бүләләр:

Беренче төркем. Ананьино культурасы керамикасы.

Хәерби шәһәрлеге керамикасы коллекциясендәге табылдыкларның 21%ы – Ананьино керамикасы. Са-

* Семенов Владимир Алексеевич (1930–1999), археолог. 1955 елда Удмурт дәүләт педагогия институтын тәмамлый. 1969 елдан башлап Удмурт фәнни-тикшеренү институтында (хәзер Россия Фәннәр академиясе Урал бүлегенең удмурт тарихы, теле һәм әдәбияты институтында). 1954 елда профессор В. Ф. Генинг җитәкчелегендә оештырылган удмурт археологик экспедицияләре составында эшли. Удмуртия территориясендә, Татарстанның төньяк-көнчыгыш районнарында тимер чорының 100 дән артык археологик һәйкәләрен ачуда катнаша. Полом культурасы (Удмуртиянең Кез районы Полом авылы янында) истәлекләрен өйрәнүгә зур өлеш кертә.

** Останина Таисия Ивановна (1947 елда туган) – тарих фәннәре докторы, Россия Табигать белеме Академиясе профессоры. Удмурт Республикасының атказанган фән эшлеклесе. 1970 елда Удмурт дәүләт педагогия институтын тәмамлый. Хәзерге вакытта борынгы җәмгыятьнең археология һәм тарих кафедрасы доценты булып эшли. 1984 елда «III–V гасырларда Урта Кама буе халкы» («Население Среднего Прикамья в III–V вв.») темасына докторлык диссертациясе яклый. 1972–1993 елларда ел саен Урта Кама буе территориясендә археологик экспедицияләр оештыра һәм үткәрә. Фәнни хезмәтләр өлкәсе: Удмуртиянең көньягында борынгы халык тарихын өйрәнү. 1997 елда «Удмурт республикасының атказанган фән эшлеклесе» исемен ала, 40 тан артык фәнни хезмәт авторы.

вытлар тасмалап ябыштыру техникасы кулланып ясалганнар, өслекләре яхшылап шомартылган; аларның формасы – горшок (озынча муенлы чүлмәк) рәвешендә. Кама тамагы тирәсендәге Ананьино чоры истәлекләренең В. Н. Марков* тарафыннан эшләнгән периодлаштырылу һәм хронология системасы буенча, Хәерби шәһәрлеге керамикасы комплексын икенче хронологик чорга (б. э. к. VII гасыр) нисбәт итәргә мөмкин[5].

Икенче төркем. Азелино культурасы керамикасы.

Горшок рәвешендәге соры, куе соры һәм охра төсендәге, эчке һәм тышкы өслекләре шомартылган савытлар табыла. Хәерби шәһәрлеге савыт-сабасы ватыклары Азелино керамикасыннан беркадәр аерылалар, шуңа күрә аларны Азелино культурасына шартлы рәвештә нисбәт итәргә мөмкин.

Өченче төркем. Имәнкискә культурасы керамикасы.

131 савыт-саба ватыгы җыела. Археологлар мәгълүматлары буенча, савыт-саба кулдан әвәләп эшләнгән, тышкы һәм эчке өслекләре йомшак предмет белән шомартылган, керамика пөхтә эшкәртелгән – шома өслек шуны күрсәтә. «Имәнкискә культурасы истәлекләрен тикшерүче П. Н. Старостин** шундый үзенчәлекле читле савытларны Б төркеменә нисбәт итә[6]; алар, аның фикеренчә, тигезсез һәм шома булмаган савытларга караганда, торулыкларда һәрвакыт сирәгрәк очрыйлар»[7].

Хәерби шәһәрлегендәге казу эшләре вакытында төрле катламнарда һәм югарылыкта 2711 сөяк табыла. Өске катламда табылган сөякләрнең зур өлеше башлыча Азелино һәм Имәнкискә культураларына карый. 352 сөякне тикшерүнең нәтиҗәсе түбәндәгечә: 40,6% – дуңгыз, 33,5% – ат, 24,4% – мөгезле эре терлек, 1,5% – мөгезле вак терлек сөякләре. Биредә ачыклык кертү сорала, Т. И. Останина фикеренчә, әлеге күренеш шәһәрлекнең өске катлавында (1–3 горизонтлар) терлекләрнең баш санына карата гына күзәтелә, ягъни сөякләр исәбе буенча беренче урынга ат «чыга»[8].

Шәһәрлекнең планиграфиясен өйрәнеп, Т. И. Останина-

* Марков Владимир Николаевич (1952–2005), археолог. 1979 елда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетын тәмамлый, шул ук елдан ТАССР Дәүләт музее хезмәткәре. 1985 елдан СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни хезмәткәре. 1988 елдан СССР Фәннәр академиясе институтының Ленинград бүлегендә эшли, 1989 елда «Нижнее Прикамье в ананьинскую эпоху (об этнокультурных компонентах ананьинской общности)» темасына кандидатлык диссертациясен яклый, тимер гасыр буенча белгеч. «Гремячий ключ» шәһәрлеген һәм ТР археологиясенең башка һәйкәлләрен өйрәнә. Ананьино культурасы проблемаларын чишүгә зур өлеш кертә. Фәнни хезмәтләр өлкәсе: Фин-угыр кабиләләре, Урта Идел һәм Урал буе тимер чоры. Төп тикшерелгән һәйкәлләр: Черепашье, Сорочьи Горы, Гремячий Ключ.

** Старостин Петр Николаевич (1936–2012), археолог, тарих фәннәре кандидаты, Имәнкискә культурасы буенча беренче белгеч, ТР Фәннәр Академиясе Тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре. ТР Дәүләт премиясе лауреаты. 1960 елда Мари педагогия институтын тәмамлый. 1962–1988 һәм 1991–2012 елларда Казанда ИЯЛИ КФАН СССР археология секторында, 1989–1990 елларда Казан педагогика институтының кафедра мөдире һәм проректоры. 1967 елда «Именьковские племена Нижнего Прикамья» дигән кандидатлык диссертациясен яклый. Болгар шәһәре территориясендә Малоиерусалимск чокыры янында болгар чорының беренче җирлеген ача (IX гасыр ахыры – X гасыр башы). 100 дән артык фәнни хезмәтләр авторы.

на: «Шәһәрлекнең кечкенәлеге, мәйданчык биеклекләренең кискен үзгәрешләре аркасында торак корылмалары төзү мөмкин булмаган. Уйлавыбызча, шәһәрлекнең көнбатыш яртысында табыну комплексы урнашкан, аның уртасында иң юан багана (диаметры 45 см, № 13), ихтимал, пот басып торган. Көньяк, көнбатыш һәм төньяк тарафлардан аны баганалар (№ 17, 24, 28, 15, 6) һәм артык кызу янмаган учаклар (VIII, VI, II, XIV, XIII) әйләндереп алган», – дип нәтиҗә ясый[9].

Үзәк багананы фаразланган әйләнә сызыгы буйлап урнашкан учаклар һәм баганалар белән тоташтыручы уйланма сызыклар юнәлешеннән чыгып фикер йөрткәндә, шәһәрлек мәйданчыгының Ай һәм Кояш хәрәкәте фазаларын билгеләү өчен «хронометр» буларак хезмәт итүе ихтимал. Үзәк багана аша югары Ай чыгышы ноктасын, Кояш чыгышы ноктасын (22 июнь), Кояш чыгышы ноктасын (1 сентябрь), Кояш чыгышы ноктасын (8–9 октябрь), түбән Ай чыгышы ноктасын, көньяк ноктасын, түбән Ай баешы ноктасын, Кояш баешы ноктасын билгеләү мөмкин булган. Алар буенча игенчелек эшләренең, мәҗүсилек бәйрәмнәренең календарь даталарын, җәйге Кояш торгынлыгы көнен билгеләгәннәр.

Терлек сөякләренең күпләп табылуы «шәһәрлекнең башка мәйданында, «хронометр»дан көньяк һәм көнчыгыш тарафларда корбан чалуларны күрсәтә. Мәйданчыкның территориясе дә, ныгытмалар да зур түгел. Мәйданчыкта үзәк баганалы «хронометр» урнашкан, фаразланганча, анда каһин (жрец) җитәкчелегендә шунда яшәүчеләр, яңгыр, яктылык, уңыш бирүен сорап мәҗүси илаһларга ялварганнар, ритуаль йолалар башкарганнар.

Хәерби туктаулыгы. «Татарстан Республикасының археология истәлекләре җыелмасы»нда[10] 1819 нчы номер белән авылдан көньяктарак, Мишә елгасының уң ярында тугай өстендәге терраса борынында чәчүлек җирдә урнашкан Хәерби туктаулыгы тасвирлана (70×70м). Анда Маклашеевка культурасына (Соңгы Казан алды культурасының Маклашеевка чорына) нисбәтле әвәләп ясаган керамика, тараксыман зигзаглы бизәкле соңгы чор рус керамикасы кисәкләре, известьташтан эшләнгән тегермән ташы ватыклары табыла. Хәерби туктаулыгы 1977 елда Е. П. Казаков* тарафыннан тикшерелә[11]. Коллекция Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең А. Х. Халиков исемендәге Археология институтының Археология музеенда саклана (Кир-77) (Казан археология

* Казаков Евгений Петрович (22.10.1934 елда туган), тарихчы, археолог, тарих фәннәре докторы, ТРның атказанган фән эшлеклесе (1999). 1963 елда Казан университетын тәмамлый. 1966 елда СССР КФАның Тел, әдәбият һәм тарих институты аспирантурасын тәмамлый. 2001 елдан баш фәнни хезмәткәр. 1995 елдан «Finno-Ugrica» журналы мөхәррире. 1959 елдан Татарстан территориясендә археологик һәйкәлләрне тикшерүдә катнаша. Такталачык, Олы Тархан, танки каберлекләрен, үлчәү урыннарын һәм башка археологик объектларны казу эшенә җитәкчелек итә. Хезмәтләре Идел буе Болгары тарихы һәм археологиясе, Идел-Кама буеның таш, бронза һәм тимер гасырлар тарихына карый. ТР Дәүләт премиясе лауреаты.

экспедициясенең 1977 елгы хисабы; АК, 1981, № 391).

Хәерби акча табылдыклары. А. В. Васильевның 1930 елда басылган «Татарстан республикасында Алтын Урда акчаларының яңа табылдыклары» мәкаләсендә рабфак студенты Хариз Гарифовның Татарстанны өйрәнү җәмгыятенә (ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1928 ел 10 июль карары белән оештырыла һәм 1930 елга кадәр эшли) «Татарстан республикасының Лаеш районы Хәйриби авылы* тирәсендә» табылган 5 татарча язулы көмеш акча тапшыруы хакында белдерелә. Студент сүзләренә караганда, авыл халкы шундый ук «5 тиенлек көмеш акча зурлыгындагы, татарча язулы, араларында Хәбибулла хан исеме сугылганнары ешрак очраган көмеш акчаларны»[12] еш таба торган булган. Алтын Урда идарәчеләре арасында Хәбибулла хан исеме очрамавы сәбәпле, А. В. Васильев, ихтимал, әлеге хөкемдар Алтын Урдада һиҗри буенча 764–770 (милади 1362–1368) елларда идарә иткән Габдулла хан булса кирәк, дип фаразлый.

Барлык табылган акчалар Алтын Урда дәверенә карый:

2 акчадагы язуларда Шадибәк хан (һиҗри 802–809, милади 1400–1407 елларда идарә иткән) исеме укыла. Шадибәк исеменнән акчалар Азак, Болгар, Кырым, Каффа, Урда, Сарай, Хаҗитархан, Харәзем, Шемаха шәһәрләрендә сугылган.

– 2 акчадагы язуларда Булат хан исеме укыла (Пулад хан – Шадибәк хан улы, һиҗри 810–813, милади 1408–1411 елларда идарә иткән);

– 1 акчада, ихтимал, Тимер хан (һиҗри 813–814, милади 1411–1412 елларда идарә иткән).

Үзара низаглар, эчке ызгышлар, тәхеткә дәгъва кылган бертуганнар арасында барган һәлакәтле сугышлар, ханнарның еш алмашынуы Алтын Урданың таркалуына китерә. Шадибәк хан, Булат хан (Пулад хан) идарәсе тирән икътисади һәм сәяси кризис чорына туры килә, болар барысы да тискәре күреншләрнең, иҗтимагый ризасызлыкның көчәюенә, сәүдәнең һәм һөнәрләрнең сүнүгә йөз тотуына сәбәп була. Үзбәк һәм Җанибәк ханнар заманында сугылып, бизәкләренең һәм язуларының төгәллеге, пөхтәлеге ягыннан аерылып торган акчалар белән чагыштырганда, әлеге дәвердә сугылган акчаларның сыйфаты да түбән була.

Хәерби авылында табылган акчаларны А. В. Васильев нәфислек һәм төгәллек җәһәтендә кайтыш акчалар исәбенә кертә. Мәсәлән, ул: «Шадибәк хан акчаларының берсе (№ 1) Болгарда сугылган, әмма елы тулысынча күрсәтелмәгән. Язуларда сүзләр өлешчә сугылган, хан исемендәге хәрефләр читкә сибелгән», – дип билгеләп уза. Әлеге акчада гарәп хәрефләре белән түбәндәге язу урнаштырылган[13]:

| | |
|---|---|
| әс-солтан | Султан |
| Шади (бәк) | Шади (бек) |
| газим | Верховный |
| хан | Хан |
| Халид мә | Да длится царствование его |
| Зарб (акча сугу) | Чекан |
| Болгар | Болгар |
| 806 | 806 г. (или 809) |

* Хәзер ТРның Лаеш районы Хәерби авылы.

Акчаның йөз ягында тыгызланмаган төен рәвешендәге бизәк бар.

Икенче акча (№ 2) беренчесенә охшаш, «әмма язу штемпель белән сугылган, йөз ягында акча бизәге урнаштырылган».

Өченче акчадагы (№ 3):

| | |
|---|---|
| әс-солтан | Султан |
| …хак | (право)судный |
| … лад (Пулад) | (Пу)лад |
| Зарб (акча сугу) | Чекан |
| | Сарая |
| | нового |
| Болгар | Болгар |
| 8 | 8 |

А. В. Васильев өченче акча (№ 3) ике ханга нисбәтле – реверсы Шадибәк хан акчаларына карый, аверсы аның варисы Пулад хан тарафыннан һиҗричә 808 елда сугылган, дип фаразлый.

Дүртенче акча (№ 4) аверсындагы язу:

| | |
|---|---|
| әс-солтан | Султан |
| әл-гадел | правосудный |
| Пулад (Булат) хан | Пулад-хан |

Алдагы юл сакланмаган (ике хәрефнең өске яртылары гына күренә.

Реверстагы язу:

| | |
|---|---|
| (…) арб (зарб – акча сугу) | Чекан |
| (Бол)гар | Булгара |
| җәдид | Нового |

Бишенче акчаның (№ 5) аверсында бер генә сүз – «әл-солтан» (әс-солтан), реверсында сүзләрнең ахыргы өлешләре: …лид («халид» сүзеннән), …кә («мәликә» сүзеннән), …ер («Тимер» сүзеннән) сакланган; җыелма мәгънә «…Тимер хан, патшалыгы гомерле булсын» дип фаразлана. Димәк, әлеге акчаны Пулад хан варисы Тимер ханга, якынча 818 елга (милади 1412 елга) нисбәт итә алабыз[14].

Лаеш районының Хәерби авылы янында табылган акчаларны тикшергәннән соң, А. В. Васильев алар сирәк очраучы акчалар исәбенә керәләр, язулар акчаларның ашыгып сугылуы, материал җитмәве, укымышлылык дәрәҗәсенең һәм җитештерү рәвешенең түбән тәгәрәве турында шаһитлек итә, дип нәтиҗә ясый. Ул Хәерби авылы тирәсендә археологик тикшеренүләрне дәвам итү яңа ачышларга китерәчәк, Алтын Урданың башка ханнары акчалары да табылачагы ихтимал, дип исәпли.

**Сведения об авторах:** Галимуллина Гульшат Хабулловна, старший научный сотрудник Обособленного подразделения ГНБУ «Академия наук РТ» «Институт татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ», e-mail: kirbi2@mail.ru; Насибуллина Алсу Булатовна, научный сотрудник Центра энциклопедистики Института татарской энциклопедии и регионоведения Академии наук РТ, e-mail: buiat.alsu1971@yandex.ru; Абдуллин Халим Миннулович, кандидат исторических наук, старший научный сотрудник Музея археологии Института Археологии им. А. Х. Халикова АН РТ, e-mail: xalimabd@mail.ru.

**Аннотация:** Изучение археологических памятников населенных пунктов районов Республики Татарстан по материалам Института археологии им. А. Х. Халикова АН РТ; обогащение истории татарского села, его эпиграфических памятников.

**Ключевые слова:** Кирбинское городище, Кирбинская стоянка, Кирбинские монетные находки, археология, Т.И. Останина, Е.П. Казаков.

**Abstract:** The study of archaeological monuments of settlements in the regions of the Republic of Tatarstan based on materials from the A. Kh. Khalikov Institute of Archeology of TAS; enrichment of the history of the Tatar village, its epigraphic monuments.

**Keywords:** Kirbinskaya settlement, Kirbinskaya parking, Kirbinskaya coin finds, archeology, T.I. Ostanina, E.P. Kazakov.

БИБЛИОГРАФИЧЕСКИЙ СПИСОК

1 Галимуллина Г.Х., Насибуллина А.Б. Хәерби авылы тарихыннан сәхифәләр – Страницы истории села Кирби.– Казань: ИТЭР АН РТ, 2019. 500 с., илл.

2 Путеводитель по Научному фонду Музея археологии Республики Татарстан Института истории им. Ш. Марджани АН РТ / Отв. ред. Х.М. Абдуллин.– Казань: Изд-во «ЯЗ», Институт истории АН РТ, 2011. 220 с.; Свод памятников археологии Республики Татарстан: в 3 т. / Отв. ред. А.Г. Ситдиков, Ф.Ш. Хузин.– Казань, 2007. Т. 3. С. 229.

3 Останина Т. Кирбинское гордище на реке Меше // Finno-Ugrica. 2001–2002. № 1 (5–6).

4 Там же.

5 Там же.

6 Останина Т. Кирбинское гордище на реке Меше // Finno-Ugrica. 2001–2002. № 1 (5–6); Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г.С. Сабирзянов.– Казань: Институт Татарской энциклопедии, 2010. Т. 5: Р–Т. С. 427.

7 Останина Т. Кирбинское гордище на реке Меше // Finno-Ugrica. 2001–2002. № 1 (5–6).

8 Там же.

9 Там же.

10 НФ МА РТ ИА АН РТ. Казаков Е.П. Материалы к отчету 1977 г. Кирбинская стоянка. Рисунок № 6.

11 Там же; Татарская энциклопедия: в 6 т. / гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г.С. Сабирзянов.– Казань: Институт Татарской энциклопедии, 2006. Т. 3: К–Л. С. 17.

12 Васильев А. Новые находки золотоордынских монет в ТР // Труды Общества изучения Татарстана. Т. 1. 1930. С. 173–175.

13 Там же.

14 Там же.